КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 9 ноябрь, г.Казань № 857

Урынны – торак урын, торак урынны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану максатларында, Татарстан Республикасы торак фондының торак урыннарын һәм башка торак урыннарны бәяләү һәм тикшерү буенча ведомствоара комиссия турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урынны – торак урын, торак урынны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2006 ел, 28 гыйнвар, 47 нче карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Урынны – торак урын, торак урынны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану максатларында, Татарстан Республикасы торак фондының торак урыннарын һәм башка торак урыннарны бәяләү һәм тикшерү буенча ведомствоара комиссия төзергә.

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Урынны – торак урын, торак урынны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану максатларында, Татарстан Республикасы торак фондының торак урыннарын һәм башка торак урыннарны бәяләү һәм тикшерү буенча ведомствоара комиссия турындагы нигезләмәне;

Урынны – торак урын, торак урынны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану максатларында, Татарстан Республикасы торак фондының торак урыннарын һәм башка торак урыннарны бәяләү һәм тикшерү буенча ведомствоара комиссия составын.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 ел, 29 гыйнвар, б-93 нче боерыгы үз көчен югалткан дип санарга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 9 ноябрь, 857 нче
карары белән расланды

Урынны – торак урын, торак урынны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану максатларында, Татарстан Республикасы торак фондының торак урыннарын һәм башка торак урыннарны бәяләү һәм тикшерү буенча ведомствоара комисссия
составы

| | |
|---|---|
| Песошин Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министры, комиссия рәисе |
| Сибгатуллин Илдар Нурзада улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, элемтә, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсе башлыгы, комиссия рәисе урынбасары |
| Фролов Алексей Михайлович | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасары, комиссия рәисе урынбасары |
| Вәлиуллин Марсель Мәхсүм улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, элемтә, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсенә караган юл һәм төзелеш комплексларында инвестиция программаларын тормышка ашыру бүлеге баш киңәшчесе, комиссия сәркатибе |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Закиров Алмаз Илгиз улы | Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының Экология күзәтчелеге дәүләт инспекциясе башлыгы |
| Крайнов Сергей Аркадьевич | Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе башлыгы |
| Кудряшов Василий Александрович | Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе башлыгы |

| | |
|---|---|
| Трофимова Марина Викторовна | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары |
| Трущин Максим Владимирович | Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры – Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе башлыгы урынбасары – дәүләт янгын күзәтчелеге һәм профилактика эшләре бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Хәмзина Лена Илдар кызы | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Техник инвентарьләштерү бюросы» республика дәүләт унитар предприятиесе генераль директоры |
| Хәсәнова Ирина Александровна | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының торак күчемсез мөлкәт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары бүлеге башлыгы |
| Хөснетдинов Гадел Альберт улы | «Татинвестгражданпроект» дәүләт унитар предприятиесе генераль директоры. |

______________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 9 ноябрь, 857 нче
карары белән расланды

# Урынны – торак урын, торак урынны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану максатларында, Татарстан Республикасы торак фондының торак урыннарын һәм башка торак урыннарны бәяләү һәм тикшерү буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Нигезләмә урынны – торак урын, торак урынны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану максатларында, Татарстан Республикасы торак фондының торак урыннарын һәм башка торак урыннарны бәяләү һәм тикшерү буенча ведомствоара комиссия (алга таба – комиссия) эшчәнлеге тәртибен билгели.

1.2. Комиссия Татарстан Республикасының дәүләт торак фондына караган урынны – торак урын, торак урынны гражданнар яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану максатларында, шулай ук күпфатирлы йортны эксплуатацияләүгә кертү турында рөхсәтнамә биргән көннән биш ел эчендә күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яки реконструкцияләнергә тиешле һәм торак урын гражданнар яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип тану максатларында бәяләү һәм тикшерү өчен төзелә.

1.3. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе законнарына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урынны – торак урын, торак урынны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2006 ел, 28 гыйнвар, 47 нче карарына (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 ел, 28 гыйнвар, 47 нче карары), Татарстан Республикасы законнарына, бу Нигезләмәгә таянып эш итә.

## 2. Комиссия бурычы һәм функцияләре

2.1. Комиссия бурычы – урынны – торак урын, торак урынны гражданнар яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану, шулай ук күпфатирлы йортны эксплуатацияләүгә кертү турында рөхсәтнамә биргән көннән биш ел эчендә күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә тиешле яки

реконструкцияләнергә тиешле һәм торак урын гражданнар яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип тану өчен Татарстан Республикасының дәүләт торак фондын бәяләү.

2.2. Үзенә йөкләнгән бурычны үтәү максатларында, Комиссия түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:

урынны – торак урын, торак урынны гражданнар яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә тиешле дип тану максатларында, Татарстан Республикасының дәүләт торак фондына караган торак урыннарны һәм күпфатирлы йортларны законнар белән торак урыннарга карата билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәүне бәяләү;

торак урынны гражданнар өчен яраклы (яраксыз) дип, ә күпфатирлы йортны эксплуатацияләүгә кертү турында рөхсәтнамә биргән көннән биш ел эчендә күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә тиешле яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану максатларында, урынны бәяләү һәм тикшерү.

## 3. Комиссия эшчәнлеген оештыру һәм аның тәртибе

3.1. Комиссия составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана.

3.2. Комиссия әгъзалары комиссия утырышларында үзләре шәхсән, үз вәкаләтләрен башка затка тапшыру хокуксыз катнаша.

3.3. Комиссия эшчәнлеге белән комиссия рәисе җитәкчелек итә, ул комиссия утырышын алып бара, комиссия әгъзаларына йөкләмәләр бирә һәм аларның үтәлешен тикшерүдә тота. Комиссия рәисе булмаганда, аның вазыйфасын комиссия рәисе кушуы буенча урынбасарларының берсе башкара.

3.4. Комиссия эшен сәркатиб оештыра, ул өч эш көне алдан комиссия әгъзаларына утырышны үткәрү көне, вакыты һәм урыны турында хәбәр итә.

3.5. Комиссия эшенә җәлеп ителүче торак урын милекчесенә (аның вәкаләтле затына) хәбәр итү утырыш үткәрү көненә кадәр кимендә 15 календарь көн алдан комиссиянең тиешле утырышын үткәрү көне, урыны һәм вакыты турында мәгълүматлары булган белдерү кәгазен тапшыру турындагы хәбәрнамә белән заказлы хатны аның почта адресына җибәреп гамәлгә ашырыла.

Әлеге белдерү кәгазен әзерләү һәм билгеләнгән вакытта җибәрүне комиссия сәркатибе тәэмин итә.

3.6. Комиссия, торак урыннарны һәрьяклап һәм объектив тикшерү максатларында, комиссия эшенә проект, торак, коммуналь оешмалар белгечләрен, торак-эксплуатация оешмалары хезмәткәрләрен җәлеп итәргә хокуклы. Әлеге затлар комиссия составына керми һәм комиссия эшендә киңәш бирү тавышы хокукы белән катнаша, шулай ук үз компетенциясе кысаларында комиссия тарафыннан куелган мәсьәләләргә бәяләмә әзерли.

3.7. Комиссия утырышлары урыннар милекчеләре, торак урыннар милекчеләре һәм хак түләп вакытлыча файдалануга алучылар гаризалары йә аларның компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча дәүләт күзәтчелеге

(мәсьәләләре) органнары бәяләмәләре керүгә һәм гариза кергән көннән 30 көн эчендә кирәкле документларны әзерләүгә карап үткәрелә.

3.8. Комиссия утырышы, әгәр дә анда аның составының кимендә өчтән икесе катнашса, тулы хокуклы дип санала.

3.9. Комиссия тарафыннан урынны – торак урын, торак урынны гражданнар яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану максатларында, урыннарны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 ел, 28 гыйнвар, 47 нче карары һәм бу Нигезләмә нигезендә бәяли һәм тикшерә.

3.10. Эш нәтиҗәләре буенча комиссия Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 ел, 28 гыйнвар, 47 нче карары нигезендәге форма буенча бәяләмә рәвешендә карар кабул итә. Бәяләмә өч нөсхәдә төзелә.

3.11. Карарлар комиссиядә катнашучы әгъзаларның ачык тавыш бирү юлы белән күпчелек тавышлар белән кабул ителә. Тавышлар саны тигез булганда, комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып санала. Үз фикере булган комиссия әгъзасы аны язма рәвештә бирә. Мондый фикер бәяләмәнең аерылгысыз бер өлеше булып тора.

3.12. Комиссия бәяләмәсенең бер нөсхәсе төзелгән көннән 10 көн эчендә – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының урынны – торак урын, торак урынны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану турында боерыгы проектын әзерләү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсенә, карарның тагын бер нөсхәсе – гариза бирүчегә һәм икенчесе Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясенә җибәрелергә тиеш.

Комиссия бәяләмәсендә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгында торак урынны алга таба файдалану, йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип таныган очракта физик һәм юридик затларны күчерү вакытлары йә ремонт-торгызу эшләрен үткәрү кирәклеген тану турында күрсәтмә булырга тиеш.

_______________________________